# КАРАР
## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Шәтке торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 7 декабре** **Шәтке авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 7 декабрендә Шәтке торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Шәтке торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Шәтке авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- С. Сәйдәшев, Школьная, Молодежная, Дружба, Г. Тукай урамнарындагы юлларга вак таш җәю (вак таш җәюне оештыру, эшләрне килешү буенча түләү);
- урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, янгын автоцистернасын тоту;
- юлларны кардан чистарту;
- каты коммуналь калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту;
- зират өчен җиһазлар һәм инвентарь алу;
- җәйге чорда юл кырыйларын чабу;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча түләү);
- "Кече үзән" елгасы аша күперне ремонтлау (материал сатып алу, килешү буенча түләү);
- «Шадки»- «Шәтке» торак пункты исеме язылган стелла урнаштыру ( материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?”

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 528 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 277 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында 277 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Шәтке торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2.Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлегенең Шәтке торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Шәтке авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- С. Сәйдәшев, Школьная, Молодежная, Дружба, Г. Тукай урамнарындагы юлларга вак таш җәю (вак таш җәюне оештыру, эшләрне килешү буенча түләү);

- урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, янгын автоцистернасын тоту;

- юлларны кардан чистарту;

- каты коммуналь калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту;

- зират өчен җиһазлар һәм инвентарь алу;

- җәйге чорда юл кырыйларын чабу;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча түләү);

- "Кече үзән" елгасы аша күперне ремонтлау (материал сатып алу, килешү буенча түләү);

- «Шадки»- «Шәтке» торак пункты исеме язылган стелла урнаштыру ( материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?”

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Шәдке авыл җирлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шәтке авыл җирлеге Башлыгы: Ф. Г. Кадыйров